УДК 82

***Ситдыйкова Ч.Ф. , филология фәннәре кандидаты***

***«Language+» студиясе***

***Мәкалә «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4. санлы чарасы чикләрендә башкарылды.***

## Ф.САФИН ПРОЗАСЫНДА ЮМОРИСТИК ҺӘМ САТИРИК ЧАРАЛАР

*Аннотация: Мәкаләдә хәзерге татар прозасының күренекле вәкиле Ф.Сафинның 1980-1990 елларда иҗат ителгән хикәяләрендә сатира һәм юмор чаралары анализлана.*

*Төп төшенчәләр: проза, сатира, юмор, алым.*

***Sitdikova Ch.F., Candidate of Philological Sciences***

***Studio «Language+»***

## HUMOROUS AND SATIRICAL TECHNIQUES IN THE PROSE OF F.SAFIN

*Abstract: Humorous and satirical techniques in F.Safin's prose of 1980-1990's are analyzed in this article.*

*Keywords: prose, satire, humor, technique.*

Ф. Сафинның эпик төрдә иҗаты юморескалар, юмористик хикәяләрдән башлана. Язучының беренче хикәяләре «Татарстан яшьләре» газетында, «Чаян» журналында басыла, 1992 елда «Соңгы көз» дип аталган повесть һәм хикәяләр җыентыгы дөнья күрә.

Беренче әсәрләрендә шул еллар татар прозасындагы гомум тенденция – тормыштагы тискәре күренешләрне сәнгатьчә фаш итү омтылышы аеруча көчле була. Бу вакытта аерым ситуацияләр җентекле

тасвирлана, эчтәлек алышыну алымы кулланыла. «Нервың гына чыдасын» (1988), «Якшәмбе – ял көне» (1976) һ.б. хикәяләрдә хәзерге заманда кешеләрнең бер-берсенә карата шәфкатьсезлеге, мәрхәмәтсезлеге, дорфалыгы күрсәтелә, әхлаксызлык, көч куллану, җәбер-золым кебек күренешләр тәнкыйтьләнә. Әсәрләрдә «көчсезләрне – куркыту, көчледән – курку» фәлсәфәсен кире кагу чагылыш таба.

Автор ирониясе, мәзәкчел ситуацияләр язучының «Ярыш» (1974), «Якшәмбе ял көне» әсәрләрендә отышлы файдаланылган. Әлеге хикәяләрдә күршеләр, дуслар арасындагы мөнәсәбәтләр юмористик рухта яктыртыла, көнчелек дуслыкка, күршелеккә зыян китерүче күренеш буларак бирелә.

«Нигә кердем соң әле» (1980), «Күркә» (1981), «Ызгышлы сәфәр» (1981) әсәрләрендә язучы ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне юмор объекты итеп ала һәм ironияле карашы аша үткәрә. Фикерләре төрле булу, ызгыш чыгу аркасында ире – бер баласына, хатыны – икенче баласына кунакка китә («Ызгышлы сәфәр»). «Күркә» хикәясендә Өммикамал исемле хатын иң элек ире Әхмәтне күршесенә «эт» итеп сүгә, ә инде ахирәте Әхмәтне «күркә» дип атагач, ирен яклап чыга, аны мактый. «Нигә кердем соң әле» әсәрендә язучы ир-атны берникадәр вакытка хатын-кыз урынына куеп карый (урын һәм эчтәлек алышыну). Балалар бакчасына хатыны янына йомыш белән кергән Кави Рәхилә үтенече белән тәрбияче ролен башкарырга мәҗбүр. Ир-атның балаларга төрле «командалар» биреп, тәртип урнаштырырга теләве көлке уята. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне әсәрләрнең үзәгенә кую язучыга үзсүзлелек, гаиләдә бер-беренә юл куймау, юкка тавыш чыгару, бер-береңне хурлау кебек күренешләрнең мәгънәсезлеген күрсәтү өчен кирәк.

«Диңгез уртасында бер кораб» (1989) хикәясендә язучы текст эчендә текст бирү алымына мөрәҗәгать итә. Мөхти белән Тәкәрли телевизордан сүзсез фильм карыйлар: берсе фильмны мәгънәсез дип таба, икенчесенең

күңеле болгана, җирәнү хисе туа. Баксаң, кинофильмда күргәннәр реаль чынбарлыкны чагылдыра икән (фильм-чынбарлык янәшәлеге). Бу – тормышны читтән торып бәяләү мөмкинлеге бирә, тискәре якларны күрергә ярдәм итә. Кинофильм кешеләрнең тормышын, яшәү рәвешен чагылдыра. Хикәянең исеме символга әйләнә: диңгез – җиһан, кораб кешеләр тормышы мәгънәләрендә кулланыла. Әдип тормышта трагик һәм комик хәлләр һәрчак янәшә яшәгәнлеген ассызыклап үтә.

Ф. Сафинның «Оҗмахта яңа ел» (1977) хикәясе башлангыч чор әсәрләре арасында аерым урын алып тора. Биредә юморның гына теше үтә алмаслык хәлләр сатира чаралары ярдәмендә сәнгатьчә гәүдәләндерелә. Сатирик герой – Әхтәм Бариечның «теге» дөньядагы тормышы фани дөньядагысына каршы куела (антитеза). Әхтәм Барием Чалшайганов «ни теләсә, шуны кылана»: алдаша, хәләл булмаган «балда-майда йөзә», хатынына хыянәт итә һ.б. «Теге» дөньяда алдашу, «кара» гамәлләр кылу катгый тыела. Һәр ел азагында оҗмахтагыларның еллык гамәлләренә йомгак ясала, әлеге эш белән махсус комиссия шөгыльләнә (герой бу комиссияне фани дөньядагы райком бюросы белән чагыштыра). Фани дөньяда Яңа ел алдыннан рәис буш вәгъдәләр биреп, алдагы елга күчерелә торган булса, оҗмахта болар барып чыкмый. Оҗмах таләпләрен үтәмәсәң, «яңа елга чыгасы юк». Яңа елга чыгу – оҗмахның түренәрәк үтү дигән сүз. Әхтәм һәр елны иске елда калдырыла, оҗмах ишеге төбеннән ары китә алмый, «киләсе елда да тәртибе үзгәрмәсә, тәмугка җибәреләчәк». Сәбәбе: Әхтәм биргән вәгъдәсен үтәмәгән. Фани дөньяда алдау, хәйлә юлы, танышлык белән көн күргән рәис ахирәттә куркуга кала. Геройның сират күпере янында үз чиратын көтеп тору күренеше шул хакта сөйли: «Исемә килсәм, озын, тар гына басма алдында торам. Мондагы халык... Ата улны, ана кызны белми. Кыямәт көне икән. Басам дигәнем сират күпере булып, адәм затларын шунда гөрзиләр белән куалап кертеп торалар... Һәркемнең култык астында гамәл дәфтәре. Минем дәфтәр «Правда» гәҗите теркемәсе

кадәр. Ичмасам, ник берәр җүнле сүз булсын анда... Шулай, куркуымнан җепкә абынып егылыр дәрәҗәдә хәлсезләнеп, күпер төбенә килеп җиттем» [1, б.86].

Вакыйгалар үстерелеше дә сатирик образны тулырак күрсәтү максатына хезмәт итә. Тәмугта януын күз алдына китереп калтырана-калтырана сират күпере төбендә басып торганда, Әхтәмне янә фани дөньядан калган «танышлык» коткара: Сәхипгәрәев ярдәме белән ул оҗмахка үткәрелә, гамәл дәфтәре юкка чыгарыла – җәһәннәмгә «олактырыла».

Әсәр азагында Әхтәм Бариеч ни эшләргә белми: дусты Сәхипгәрәев, хисап эшләрендә буталчыклар чыгару сәбәпле, тәмугка озатылган, таныш-белешләре оҗмах түренә үтеп беткәннәр... «Фани дөнья булса, гариза язып башка кулайрак эшкә күчәр идем дә, монда мөмкин түгел шул»[1, б.88] дип уфтана герой. Аның Чалшайганов фамилиясе символик мәгънәгә ия: чалыш сүзеннән булырга охшый. Янәшәлекләр (геройның фани дөньядагы тормышы, оҗмахтагы тормышы), фантастик образлар (фәрештәләр), гипербола («геройның гамәл дәфтәре «Правда» газеты теркәмәсе кадәр»), антитеза (фани дөнья – оҗмах) кебек алымнар сатирик персонажны мәйданга чыгара. Сатирик характер аша язучы шундый кешеләрне эш башында тоткан җәмгыятьне бәяли.

«Ашыгыч чара» (1980) хикәясендә арттыру алымы ироник мөнәсәбәт белдерү өчен хезмәт итә. Иң элек көлкеле мохит тудырыла: җиргә сөт түгелү аркасында чебен җыела, ис чыга. Шуннан соң ашыгыч чаралар күрелүе тасвирлана: сөт түгелгән җиргә комиссия, чокыр казырга экскаватор, җирне эттерергә бульдозер җибәрелә. Яңгыр яву сәбәпле, эш туктатыла, чөнки сөт юылып бетә, ә экскаватор казыган тирән чокыр шәһәр халкына истәлеккә кала. Сөт түгелү вакыйгасы сәяси мәгънә ала.

Ф. Сафинның беренче хикәяләренә рус әдәбиятында А. Чехов, Е. Петров, М. Салтыков-Щедрин, татар әдәбиятында Ф. Яруллин, Х.

Сарьян әсәрләрендә дә очратырга мөмкин булган көтелмәгән чишелешләр хас, бу әсәрләрнең эчтәлеген тагын да мавыктыргыч, интригалы, кызыклы итә. «Иртә җитлегү» (1982), «Кодалар» (1982) юморескаларында сурәтләнгән вакыйгаларны, хәлләрне текстның азагында гына реаль бәялә булa. Әйтик, «Иртә җитлегү» дип исемләнгән юморескада егет кызны озатырга рөхсәт сорый, озата, бераз утырыйк, ди, күңелсез була башлагач, кызның ботын чеметеп ала, тегесе – «яңагыннан ут күрсәтә». Көтелмәгән финал – болар 4-5 яшьлек балалар икән. Биредә язучы Ф. Әмирхан, Г. Гобәйдуллин кебек сатириклардан килгән логик адаштыру алымын уңышлы кулланган.

1980-2000 елларда иҗат ителгән хикәяләрендә Ф. Сафин җәмгыятьтьтәге тискәре күренешләр (формальлек, кода-кодагыйлык, гаиләдә бер-береңә юл куймау һ.б.), замана кешеләрендәге тискәре сыйфатлар (ялагайлык, комсызлык, көнчелек, мәкер, мин-минлек, битарафлык һ.б.) турында сөйли, алар беренче карашка юмористик булып тоела. Бу, бигрәк тә, геройларны яратып, җылы юмор ярдәмендә характерлар итеп тудыруда күренә. Ләкин эчтәлек, төп төшенчәләрнең аңланылышы үзгәрү ирония хасил итә. Автор иронияcе исә кешенең кыйммәтен санга сукмаган җәмгыятькә, бер-беренә игътибарсыз һәм ихтирамсыз, көнчел кешеләргә юнәлтелгән. Фәлсәфи яктан, кешенең үз гамәлләренә, тирәсендәгеләргә объектив бәя бирә алмавы хакындагы фикер тоемлана. Бу юлда язучыга логик адаштыру, гипербола, мәзәкчел я гыйбрәтле ситуация (комик һәм трагик хәлләр), көтелмәгән финал, эчтәлек алышыну, янәшәлекләр, сатирик образлар куллану, антитеза кебек сатирик алымнар һәм комик чаралар ярдәм итә.

**Использованные источники:**

1. Сафин Ф. Соңгы көз: повесть, хикәяләр. Чаллы: «КамАЗ» нәшр., 1992. 86 б.